**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 4.1** **2011 елның 22 феврале**

**Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 28 гыйнварында кабул ителгән «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында»гы 6 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 6 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

-Түбән Кама шәһәре Мэрының һәм аның урынбасарларының айлык акчалата бүләкләре күләме (16.1 нче кушымта);

- Түбән Кама шәһәре Мэрының һәм аның урынбасарларының тиешле елларын эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр күләме һәм аны түләү тәртибе (16.2 кушымта).

2. Түләүләр:

Түбән Кама шәһәре Мэрының һәм аның урынбасарларының айлык акчалата бүләкләре 2011 елның 1 мартыннан бирле башкарыла;

Түбән Кама шәһәре мэры һәм аның урынбасарларының тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр 2012 елның 1 гыйнварыннан башкарыла.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э.Р.Долотказинга йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А. Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2011 елның 22 февралендәге
4.1 номерлы карарына
**1 нче кушымта**

Түбән Кама шәһәр Советының
2009 елның 28 гыйнвардагы
6 номерлы карарына
**16.1 нче кушымта**

**Түбән Кама шәһәре**
**Мэры һәм аның урынбасарларының**
**айлык акчалата бүләкләү күләме**

| Хезмәт хакы буенча төркем (халык санына карап муниципаль берәмлек башлыгы) | 4 группа<br>100 дән 250 меңгә кадәр кеше |
|---|---|
| Түбән Кама шәһәре Мэры | 6612 - 72728 |
| Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары | 15870 - 24603 |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р.Долотказина

Түбән Кама шәһәр Советының
2011 елның 22 февралендәге
4.1 номерлы карарына
**2 нче кушымта**

Түбән Кама шәһәр Советының
2009 елның 28 гыйнвардагы
6 номерлы карарына
**16.2 нче кушымта**

**Түбән Кама шәһәре Мэры һәм аның урынбасарларының тиешле елларда эшләгән өчен айлык өстәмә түләү күләме һәм тәртибе**

1. Түбән Кама шәһәре мэры һәм аның урынбасарларының тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә муниципаль вазыйфада вәкаләтләрне гамәлгә ашыру срогына бәйле рәвештә түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

| Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру срогы муниципаль вазыйфада | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 20 |
| 10 елдан артык | 25 |

2. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль вазыйфада айлык өстәмә билгеләү өчен вәкаләтләрне гамәлгә ашыру срогы җирле үзидарә органының хокукый акты белән билгеләнә, анда вазыйфаи зат муниципаль вазыйфа били, җирле үзидарә органының хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә төзелә торган муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе карары нигезендә билгеләнә.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р.Долотказина